ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.10.2019 г. Заинск № 555

**«2020 елга «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслары белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормаларын раслау турында”**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик рекомендацияләрне раслау турында» 545 нче карарының (5.07.2010) 3 нче пункты нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45нче маддәсенә таянып, башкарма комитет

**карар бирә:**

1. 2020 елга түбәндәгеләрне расларга:

2020 елга балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормаларын;

Махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны мәктәпләргә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында Положениене.

2. ”Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

Әлеге карарның 1нче пунктында расланган балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормалары нигезендә финанслауны.

3. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны муниципаль район массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф идарәсе башлыгы Л.Р.Печинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы башкарма
комитетының
«21» 10 2019 № 555
карары белән расланган

**2020 елга балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативлары**

| Автотранспорт чарасының исеме | Ике ставкалы норматив размеры | |
|---|---|---|
| | Бер транспорт чарасына ставка, елга сумнарда | автотранспорт чарасының 1 километр йөрүенә ставка, сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
башкарма комитетының
«21» 10. 2019 №555
карары белән расланган

**Балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында**
**Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1Әлеге положение балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә (муниципаль хезмәт) бәяне исәпләү механизмын билгели.
1.2.Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе отчет чорына муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе, автотранспорт чараларының саны һәм автотранспорт чарасының фактта йөрүенә нигезләнеп исәпләп чыгарыла.
1.3Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен муниципаль район башкарма комитеты тарфыннан раслана.
Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чарасының фактта йөрүе турында мәгълүмат Татарстан Республикасында аерым төр транспорт чараларының бердәм мониторинг системасы мәгълүматлары буенча отчет елында расланган маршрут кысаларында фактта йөрелгән итеп кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе расчеты

2.1. Муниципаль берәмлектә бәя түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:
$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе;
$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта йөрүе, километрлар;
$NF_{km_m}$ - бер километрга балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативлары ставкасы, сумнар;

$NF_{as\,m}$ - бер автотранспорт чарасына балаларны күчереп йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативлары ставкасы, сумнар;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлеге;

$m$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең исемнәре;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең саны.